БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 октябрь 2020 ел № 13

**Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Кушымта нигезендә Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Балтач район Советының
2020 елның 9 октябреннән
13 номерлы карарына
кушымта

**Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе**

1. Әлеге Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең (алга таба - Район) җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә эшләнде.

2. Район составына керүче аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә әлеге җирлекләр бюджетларыннан район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен башкаруны аларга тапшыру турында Районның җирле үзидарә органнары белән килешү төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта Районның җирле үзидарә органнары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Районның җирле үзидарә органнарына аерым вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә Җирлек территориясендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлекләр вәкаләтләренең бер өлешен Районга тапшыру өчен, Татарстан Республикасы Балтач район Советы Район составына керүче авыл җирлекләре Советларына җирлек вәкаләтләренең бер өлешен аларга тапшыру тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә. Аерым вәкаләтләрне тапшыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләрнең инициаторлары булып Балтач муниципаль районы җирлекләре Советлары да булырга мөмкин.

4. Вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру мәсьәләләре Татарстан Республикасы Балтач район Советы һәм Район составына керүче авыл җирлекләре Советлары утырышларында карала һәм карарлар рәвешендә рәсмиләштерелә.

5. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең вәкаләтләрен тапшыру турындагы килешүләр әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары арасында турыдан-туры төзелә.

Күрсәтелгән килешүләр билгеле бер вакытка төзелергә, эчтәлегендә аларның гамәлләрен туктату, шул исәптән вакытыннан алда туктату, нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләр, тапшырыла торган вәкаләтләрне

гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларның әлеге өлештә күрсәтелгән еллык күләмен билгеләү тәртибе булырга тиеш, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

6. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында, бюджет законнары нигезендә, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар каралган Район һәм җирлекләр бюджеты турындагы карарларга үзгәрешләр кертелә.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрне формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Финанс чараларын максатсыз файдаланган очракта, алар җирлек бюджетына ун көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

7. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта, түләүсез вакытлы файдалану килешүе нигезендә муниципаль мөлкәт тапшырыла.

Түләүсез файдалану килешүе вакытлы була һәм килешү гамәлдә булу срогына төзелә.

8. Бюджет процессын оештыру һәм җирлекләрнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу буенча килешүләр нигезендә тапшырылган аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Районның җирле үзидарә органнары үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланалар.

9. Вәкаләтләрен тапшырган җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны соратып ала.

10. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- Яклар килешүе буенча;

- берьяклы тәртиптә, бер Як үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта.

11. Килешүнең гамәлдә булу вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Район җирле үзидарә органы вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән файдаланылмаган финанс чараларын, матди ресурсларны һәм мөлкәтне кире кайтара.

12. Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедураларын үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.